ҖАЕ БАР

Татарстанда җитештерелүче бензинның сыйфатын яхшырту юллары билгеле

> 2

АВЫЛДА КҮБРӘК

Авыл медицина хезмәткәрләренә түләү азрак, дип уйлаучылар ялгыша

> 2

ҮСТЕРМӘСӘҢ, ТҮЛӘРГӘ!

Хәзер әтиләр «тәрбия хакы»н балага гына түгел, үзләренә дә таләп итә ала

> 3

БЕРЛӘШҮ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 122 (29089) | Чәршәмбе | 23 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

КУЯН КУАР ЧАК ТҮГЕЛ

Ипи-сөт бәясе арта! Ил халкын әнә шулай дип кисәткәннәр. Әйтүләренә караганда, кибет киштәсендәге кайбер төр азык-төлек бәяләре якын арада ук 20 процентка кадәр кыйммәтләнергә мөмкин. Моңа ышаныргамы? Бәяләр арту өчен җирлек бармы? Бу хакта белгечләрдән сорадык.

«Опоры России» иҗтимагый оешмасы вәкиле Алексей Каневский бу көннәрдә бик күпләрне пошаманга салды. Халыкның кесә ягы болай да чамалы. Мәскәүдәге бүлекнең Икътисад комитеты җитәкчесе исә, азык-төлек бәяләре якын арада ук 20 процентка кадәр кыйммәтләнергә мөмкин, дип белдерде. Алексей Каневский әйтүенчә, бигрәк тә ит, сөт, йомырка, шикәр комы, атланмай кебек көн дә табында торучы ризыкларның бәясе югары «сикерергә» мөмкин. Аерым алганда, ипи 10 процентка артачак, дигәннәр. Сәбәпләре дә билгеле: сум арзанаю, инфляция кебек телдә бөтерелгән икътисадый күрсәткечләргә ашлык килешүе туктатылуны да өстәгәннәр. Дөрес, илнең Авыл хуҗалыгы министрлыгы бу уңайдан, икмәк бәясе артуга җирлек юк, дип белдерде.

– Чимал бәясеннән чыгып караганда, якын арада бәяләр артырга тиеш түгел, – ди Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов. – Шул ук ит, сөт җитештерүчеләрне алсак, аларның бәяләре артмады бит. Быел корылык булгач, уңыш кимрәк булыр да бөртеклеләргә бәяләр үсәр дип фаразлаган идек. Тик алай булып чыкмады. Бүген уртача уңдырышлылык гектарыннан 26 центнер тәшкил итә. Минем фаразлавымча, бөртеклеләрдән тулаем җыем 3,8–4 миллион тонна тирәсе булачак. Бу – республиканың үз ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерергә җитә. Әле артып та калачак. Балтач районындагы бер хуҗалыктан алган мәгълүматларга караганда, бүген бодайның бер центнерын 850 сумга саталар. Димәк, чималга бәя үсмәгән. Киресенчә, алдагы еллар белән чагыштырганда, бөртеклеләрнең бәяләре 1,5 тапкыр кимеде. Сөт сату-алу мәсьәләсендә дә шул ук хәл: быел сөтнең бер литрын сатып алу бәясе узган ел белән чагыштырганда 14–15 сумга түбәнрәк. Шуңа күрә азык-төлек кыйммәтләнүгә объектив шартлар юк.

Азык-төлек кибетләрендәге вазгыятьне белергә теләп, якын-тирәдәге сату нокталарын «ВТ» хәбәрчесе дә йөреп кайтты. Сатучылар бәяләр кыйммәтләнү

Илдар Мөхәммәтҗанов

турында әлегә хәбәрдар түгел булып чыкты. Киштәләрдә дә «тынлык». Киресенчә, кайбер азык-төлеккә бәяләр төшкән кебек тә тоелды. Башкаладагы кибетләрнең берсендә акция белән ак ипине – 19, сыйфатлы көнбагыш маен – 90, кечкенә кап атланмайны 80 сумга сатып алырга мөмкин.

Икътисад белгече Илдус Сафиуллин әйтүенчә, бәяләр үсү өчен кайчак әнә шундый имеш-мимеш тә җитә.

– Бүген доллар кыйммәтләнү, инфляция, девальвация турында ялкаулар гына сөйләшми. Эшнең нидә икәнен тәгаен аңларга тырышучы юк, ә менә ипи-сөт кыйммәтләнә икән дип, кибеттә чират хасил булырга бик мөмкин. Нишләтәсең, кирәкмәгәнгә капчыгы белән дөге, карабодай, токмач ише азык-төлек сатып алучылар элек тә булды, хәзер дә бар. Шул рәвешле үзебез үк бәяләрне «кыздырабыз». Болай эшләргә һич кенә дә ярамый, – ди белгеч.

Илгизәр Гайнетдинов та, бәяләрне ясалма рәвештә арттырырга мөмкиннәр, дигән фикердә.

– Кайберәүләрнең табыш артыннан куарга тырышуы ахыр чиктә гади халык кесәсенә сугарга мөмкин, – ди ул. – Бу – күбрәк спекулятив фактор. Җитештерүчеләр чыгарган продукциянең бәясен беркем дә артык тикшерми. Нигезләме алар куйган бәя, әллә юкмы? Менә шуны контрольдә тотарга кирәк. Гомумән алганда, бүгенге инфляция шартларында, ә ул еллык күрсәткечләр буенча 10 процент чамасы тәшкил итәр дип уйлыйм, җитештерүгә бәйле чыгымнар азмы-күпме артачак. Үзәк банк төп ставканы да 12 процентка кадәр күтәрде. Шул ук сатучы, эшкәртүче кредит хисабына яши икән, аңа хәзер бурычны 17–20 процент белән бирәчәкләр. Менә шушы очраклар гына бәяләрдә чагылырга мөмкин. Тик бу да шарт түгел. Сату өлкәсендә эшләүчеләрнең әйләнештә үз акчалары юк, алар баштанаяк кредит хисабына гына яшиләрдер дип уйламыйм.

АЗЫК-ТӨЛЕКНЕҢ УРТАЧА БӘЯЛӘРЕ (сумнарда)

Исеме	2023 елның 18 гыйнварына	2023 елның 16 августына	Арткан/кимегән
Сыер ите (кг)	491,85	496,13	↗
Атланмай (кг)	674,72	667,69	↘
Көнбагыш мае (л)	128,15	120,9	↘
Сөт (л)	66,34	67,69	↗
Йомырка (10 данә)	77,65	72,07	↘
Шикәр комы (кг)	64,17	72,87	↗
Он (кг)	45,55	44,51	↘
Кара ипи (кг)	61,17	62,51	↗
Бәрәңге (кг)	27,93	40,58	↗
Суган (кг)	30,52	49,08	↗

ТР Дәүләт алкоголь инспекциясеннән

Сан

Агымдагы елның икенче чирегендә Татарстанда минималь куллану кәрзине 22 мең 22 сум тәшкил иткән. Ел башында исә әлеге сан, узган елның дүртенче чирегe белән чагыштырганда 663 сумга кыйммәтләнеп, 21 мең 805 сум булган.

Эшләгәнгә түлиләр

69609 сум. Татарстан аграрийларга иң югары хезмәт хакы тәкъдим итә торган Идел буе федераль округы төбәкләре исемлегенә өчлегенә кергән. Бу хакта hh.ru хезмәтенең матбугат үзәге хәбәр итә.

Беренче урынны Мари Эл били. Анда кыр уңганнарына 90924 сум акча тәкъдим итәләр икән. Авыл хуҗалыгы тармагы эшчеләренә иң аз акчаны Ульяновск өлкәсендә түлиләр. Бу – 45 мең сум.

Июль аенда Идел буе агросәнәгать комплексы өлкәсендәге белгечләргә ихтыяҗ июнь дәрәҗәсендә сакланып калган. Бары тик алты төбәктә генә, шул исәптән Татарстанда да (+7%) ихтыяҗ арту күзәтелгән.

Хата тапканга – бүләк

Хата тапсаң, бүләкле буласың. Татарстан һәм Казан халкын мәгълүмат, элмә такталарда, топографик билгеләрдә, юл күрсәткечләрендә һәм торак йортлардагы татар телендә язылган язуларда хаталарны ачыклау буенча конкурста катнашырга чакыралар.

Катнашучыларга «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша фотолар җибәрергә тәкъдим ителә. Моның өчен телефонга мобиль кушымта урнаштырырга, теркәлү узарга һәм «Исемнәрдә һәм язуларда хаталар» категориясен сайларга кирәк. Бәйгедә катнашу өчен элмә такта тулысы белән күрсәтелгән фотоматериаллар белән (аның нинди оешмага караганы күренергә тиеш) хәбәр җибәрү, төгәл адресны күрсәтү мөһим, дип кисәтә оештыручылар. Конкурс җиңүчеләре берничә номинациядә билгеләнәчәк, бүләкләү тантанасы исә 2023 елның дүртенче кварталында узачак. Алар диплом һәм акчалата бүләкләр алачак.

Исемлек тулыланган

Россия Мәгърифәт министрлыгы эшче һөнәрләргә бәйле яңартылган исемлекне раслады. Анда 5110 һөнәр кертелгән.

Исемлектә ихтыяҗ булган 250 яңа профессия дә бар. Моннан тыш пилотсыз авиация системалары операторы, автомехатроник, транспорт куркынычсызлыгы бүлекчәсе инспекторы, 3D бастыру буенча оператор, коткаручы, флорист, фитнес-инструктор кебек һөнәрләр дә өстәлгән.

Исемлектән чыгарылган һөнәрләр рәтендә вахтер, кучер, урам себерүче, савыт-саба юучы, чүпрәк кайнатучы (варщик тряпья) бар.

Нәрсә? Кайда? Кайчан?

Бар күңеллелек бөтен дөньяда...

Август аен йомгаклау, җәй белән хушлашу гына түгел. 30 августта Татарстан халкы, кунаклар Республика һәм шәһәр көнен билгеләп үтәчәк. Елдагыча зурлап: җыр-бәйрәм, уен-көлке, салют белән!

БӘЙРӘМ КҮЧТӘНӘЧЕ

➤1983–1986 елларда ТАССР Югары Советы президиумы рәисе булып торган Әнвәр Баһаутдинов истәлегенә мемориаль такта ачылачак. Аны Маяковский урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан йорт фасадына урнаштырачаклар.

➤«Светлая Долина» торак комплексы территориясендә Нокса елгасы яр буенда күптән көтелгән парк ачылачак. Шушында ук концерт та булачак.

➤Горький исемендәге паркта спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрнең һәм спорт ветераннарының традицион җиңел атлетика кроссы, шахмат турниры, башка төрле ярышлар, 13 яшьтән 14 яшькә кадәрге егетләр һәм кызлар арасында 3х3 баскетбол уены оештырыла.

➤Татарстан Рәисе чакыруы буенча бу көнне Казанга Олимпия чемпионы Евгений Плющенко командасы килә. Якыннары хәзерге вакытта махсус хәрби операция зонасында булган гаиләләр өчен «Татнефть Арена»да боз тамашасы күрсәтеләчәк.

ӘЙЛӘН-БӘЙЛӘН ҺӘМ БӘЙРӘМ

➤«УРАМ» экстрим-паркында музыка фестивале була. Фестиваль иртәнге 10нан кичке 10га кадәр дәвам итәчәк.

➤Кабан күле яр буенда сәгать 12дә «Милли кием» фестивале башланачак.

➤13.00 сәгатькә Казан Кремле мәйданчыгында Tat Cult Fest фестивале башланачак.

➤Көндез Казан ипподромында ат чабышлары көтелә.

➤Камал театры каршындагы мәйданда «Уйнагыз, гармуннар!» фестивале һәм флешмобы узачак. Гармун көйләре астында музыкантлар һәм артистлар шәһәр урамнарын әйләнәчәк. Алар үзәк урамнардан Беренче Май мәйданына кадәр барачак. Башлана – 11.00 сәгатьтә.

➤Кичен Игенчеләр сарае каршында «Казан көзе» опера фестивале ачыла. Классик әсәрләр тыңларга яратучыларны 19.30 сәгатькә чакыралар.

➤«Казан» гаилә үзәгендә бәйрәм программасы 12.00 сәгатьтә башлана. 17.00дә Казан шәһәр филармониясе солистлары, Гүзәл Уразова, Ришат Төхвәтуллин чыгышлары көтелә. Кич исә концертны Мәскәү кунаклары дәвам иттерәчәк. Халык алдында Клава Кока һәм Jony чыгыш ясаячак. Монда ук «Ак барс» хоккей клубының яңартылган составын тәкъдим итү дә булачак. Сүз уңаеннан, ике җырчы да – команданың шәһәргә бәйрәм бүләге.

➤22.00 сәгатьтә Казансу өстен музыкаль фейерверк бизәячәк. Аны хәтта «Болгар радиосы» ешлыгына кушылып ишетергә мөмкин. Шулай ук ТНВ каналында трансляция дә планлаштырылган.

Күңел ачу мәйданчыкларында сәүдә дә гөрләячәк. Әлбәттә, башкала юлларын ябу да каралган. Шуңа күрә халыкны юл хәстәрен алдан күрергә өндиләр. Моннан тыш, салют тәмамланганнан соң, тамаша урыннарыннан өстәмә автобуслар китәчәк. Метро да соңга кадәр эшләячәк.

Татарстанның башка район-шәһәрләрендә дә бәйрәм чаралары көтелә. Китапханә, мәдәният йортларында концерт, күргәзмә, интерактивлар оештырылачак. Кыскасы, беркемгә беркайда күңелсез булмаячак! Бәйрәм үзебезнеке!

Сүзгә-сүз

realnoevremya.ru

Рөстәм РАВИЛОВ, «Сугышчан хәрәкәтләр ветераннары берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе:

Безгә ветераннар эшләре буенча министрлык кирәк. Ник дигәндә, күп кенә инвалидлар читтә кала. Алар эшкә урнаша алмый, торагы юк, сәламәтлеге чамалы. Әле бит вафат булган егетләрнең әниләре дә бар. Аларга да ярдәм кирәк. Үз бизнесы булганнардан бу гаиләләргә ярдәм итүләрен сорар идем. Миңа кагылмый, дип кенә утырырга ярамый.

(«Реальное время» басмасына биргән интервьюдан)

РОССИЯДӘ – ЭШ

«Работа.ру» һәм «Подработка» хезмәтләре ачыклаганча, Россиядә яшәүче һәр дүртенче кеше көзгә эш урынын алмаштырырга теләли яисә өстәмә керем чыганагы эзли.

НӘРСӘ ӨЧЕН?

23%	сәламәтлеккә бәйле проблемаларын хәл итәргә
23%	керемен арттырырга
12%	ремонт башларга
12%	яңа һөнәр үзләштерергә
6%	машина сатып алырга
4%	эштән китеп, башка эшләмәскә

КЕМНӘР ҖЫЕНА?

28% >> ир-атлар

23% >> хатын-кызлар

Рецепт кирәк

Билгеле булганча, даруханәләрдә дару сату буенча үзгәрешләр бу елның 1 сентябрендә генә гамәлгә керергә тиеш. Шуңа да карамастан, Россиянең кайбер даруханәләре рецептсыз гына дару сатуны инде туктаткан.

Рецепт белән генә алырга мөмкин булган дарулар рәтенә йөрәк авырулары, диабет, бронхиаль астма, антибиотиклар керәчәк. Шул ук вакытта фармацевт рецепт мәгълүматларын дарулар әйләнешен мониторинглауның цифрлы системасына тапшырырга тиеш булачак. Югыйсә даруханәгә штраф янаячак.

Сүз уңаеннан, Бәйсез даруханәләр ассоциациясе директоры, фармацевтика ассоциацияләре альянсы башлыгы Виктория Преснякова, Россиядә барлык даруларның 70 проценты рецепт белән генә сатыла торган, дип белдергән иде.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СУКТЫҢ ДА КАЧТЫҢ ТҮГЕЛ

Планетада глобальләштерүнең тәгалләнү билгеләре торган саен ешрак күренә. Аргентинада беренчел сайлауларда җиңеп баручы президентлыкка кандидат Хавьер Милей Кытайны кумалмый, аның белән мөнәсәбәтләрне өзәргә вәгъдә итә. Шунысы кызык: Кытай Аргентинага бурычларын түләргә булыша. Хәер, ул ярдәмнән әллә ни файда күренми. Ил дефолт алдында, инфляция котырына, девальвация рекордлы. Үзәк банкның төп ставкасы ул илдә 118 процентка кадәр күтәрелде. Песоның девальвациясе дә быел инде 114 процентка җитте. 11 августта долларга 287,4 песо бирсәләр, 14 августта инде 365,5 песо сорыйлар иде. Инфляция белән девальвация бер-берсе белән узыша һәм төп ставканы күпме генә күтәрмә – файдасы юк. Аргентина мисалы моны яхшы дәлилли. Хавьер Милей хакимлеккә килсә, Үзәк банкны юк итәргә, песо урынына да доллар кулланырга ниятли.

Һиндстан да глобальләштерү тәгәрмәченә үз кусәген тыгарга җыена. Җирдә сирәк очрый торган дүрт металл: литий, бериллий, ниобий һәм тантал экспортын туктатырга уйлый. Бу металлар сәнәгатьнең оборона, аэрокосмик һәм аккумулятор җитештерү тармаклары өчен алыштыргысыз мөһим.

Иран – Америка каршылыгы хәлиткеч яңа этапка кучү белән яный. Американнар дистә еллар буе нефть эмбаргосы кертелгән илләрнең танкерларын кулга төшерү һәм «кара алтын»ны бушату белән шөгыльләнде. Сәддам чорында Гыйрак шуннан интекте. Хәзер Иран зыян күрә. Берничә ай элек алар Иранның Suez Rajan судносын кулга төшергәннәр һәм соңгы көннәрдә аның нефтен бушата башлаганнар иде. Иранның Тышкы эшләр министрлыгы вәкиле Насер Канани матбугат конференциясендә: «Иран кул кушырып утырмаячак», – дип белдерде, американнарның гамәлен «пиратлык» дип атады. «Сук һәм кач» дип аталучы эпоха тәгалләнде, – диде ул. – Иран үз халкының хокукларын бозучы теләсә нинди һөҗүмгә җавап бирәчәк».

Фарсылар соңгы айларда Россия үрнәгендә нефть экспортын кискен арттыралар. Май – июнь айларында көнгә 1,6 миллион баррельгә җиткерделәр. Бу 2022 елның шул чоры белән чагыштырганда ике тапкыр диярлек күбрәк.

Глобаль державалар зур кризис фонында үзләренең элекке йогынтыларын югалта. Фарсылар белдерүе нефть сәүдәсе өчен көрәш фронтында кораллы бәрелеш белән яный.

Россиядә

ӘЛЛӘ ФЕЙК, ӘЛЛӘ ЧЫН

Россия икътисадчыларының байтагы, илдә сикерешле инфляция көтелә, диләр. Берникадәр паузадан соң сум девальвациясе дә дәвам итәр, диючеләр аз түгел. Рубль болай да иң зәгыйфь өч валюта исемлегендә өченче урынга басты инде. Яңа девальвация көзге төбәк сайлауларыннан соң башланыр, дип фаразлаучылар бар. Чиратта Президент сайлау да торуын искә алсак, үзәк хакимиятләр сум курсын авызлыкта тотарга тиешләр. Әмма хакимиятләрнең көче җитми торган объектив сәбәпләр бар.

Сикерешле инфляцияне гиперинфляция алыштырыр, дип куркытучылар да күренә. Без туксанынчы елларда бер уздык инде ул мәктәпне, шуңа бик алай калтырап ук китмибез. Кесәдә миллион сум акча йөртәсең, әмма кәефең миллионерныкы түгел. Росстат бүген үк яшь гаиләләр тамакларын кыса дигән мәгълүмат бирә. 2022 елда аларның азык-төлек куллану күләме 2021 ел белән чагыштырганда 8–22 процентка кимеде, ди. Булса булыр, ипотека кредиты түләүче гаилә бик әллә ни туарылып китә алмаячагы билгеле инде. Хәзер яшьләр кредит өстенә кредит та рәсмиләштерә, фатир гына түгел, затлы машина һәм башка уңайлыкларга тиз ирешергә тели.

Мәскәүдә дизель ягулыгының литры 60 сумга җитте, диләр. Мотор ягулыгы машинаны гына түгел, инфляцияне дә алга этәрә, бу – күптәнге хакыйкать. Бәя күтәрелүгә генә түзәрсең, «Известия» газетасы Кырымда ягулык дефициты башланды дигән хәбәр урнаштырган әле. Дефицит югары бәягә караганда да начаррак.

Телеграм-каналда көзгә икмәк 10 процентка кыйммәтләнәчәк дигән хәбәр таратыла. Икмәк пешерүчеләр моның сәбәпләрен сумның девальвациясе, ашлык килешүеннән чыгу һәм санкцияләр, дип әйтәләр, ди, имеш. Ашлыкка һәм онга бәяләр 20 процентка арткан, ди, импорт җиһазларны ремонтлау бәясе 50 процентка үскән. Россиянең Авыл хуҗалыгы министрлыгы бу хәбәрләрне кире кага, «фейк» дип атый. Дөресме, фейкмы икәнен тикшереп карау вакыты ерак түгел, көз бусагада гына.



ru.freepik.com

КИҢӘШЛЕ ЭШ

Рәсми Татарстан

Татарстанда җитештерелүче бензинның сыйфатын яхшырту юллары билгеле. Республикада заманча датчиклар җитештерүне дә җайга салырга тәкъдим иттеләр. Ә сәнәгать тармагы өчен белгечләрне вуз эскәмиясендә утыручылар арасыннан эзләячәкләр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖнең Директорлар советы утырышын үткәрде.

Республикада экологик классы 5 һәм аннан да югарырак тәшкил иткән автомобиль ягулыгы җитештерү эшен җайга салу мөмкинлеген тикшерделәр. Топчиев исемендәге нефть химиясе синтезы институты директоры урынбасары Константин Дементьев сүзләренә караганда, бүген бөтен дөньяда алкилбензинга карата кызыксыну арта.

– Илдә җитештерелүче башка төр ягулыклардан аермалы буларак, ул Таможня берлеге таләпләренә җавап бирә, – дип аңлатты Константин Дементьев. – Россиядә елына 2 миллион тонна алкилбензин җитештерелә. Шундый корылмаларның берсе Электрогорск шәһәрендә дә бар. Аның куәте тәүлегенә 1 тонна калдыкларсыз ягулык тәшкил итә. Мондый сәнәгать ТАИФ-НК яки ТАНЭКОга да туры килә. Әлеге заводларның сәнәгать мөмкинлекләре ярдәмендә өстәмә рәвештә елына 250 мең тоннага кадәр алкилбензин җитештереп булачак.

«Татнефтехиминвест-холдинг» генераль директоры Рафинат Яруллин әйтүенчә, әлеге тәкъдим ТАИФ-НК өчен аеруча да кызыклы булачак.

– «Татнефть»тә җитештерелүче бензин болай да начар түгел, ул республикада иң яхшысы. Ә менә ТАИФ-НК да әлеге технологияне кулланырга мөмкин, – диде ул.

Татарстан Рәисе республикада заманча электрон җайланмалар җитештерә башлауга бәйле тәкъдимне дә карап тикшерергә кушты. Импортны алмаштыруны истә тотып, әлеге мәсьәләнең әһәмиятен дә билгеләп үтте ул. Үзебездә җитештерелгән «акыллы» датчикларның бәясе белән дә кызыксынды.

– Чит илнекеләргә караганда арзанрак, – диде «Вектор» оешмасының финанс директоры Алексей Фомичев.

Лак-буяу, ремонт материаллары, төрле җилемнәр җитештерүче «Хома» компаниясе генераль директоры урынбасары Константин Ширшин белдергәнчә, бүген әзер товарны озатуга бәйле кыенлык юк. Чит ил компанияләре ил базарыннан киткәч, безнекеләргә яңа мөмкинлекләр ачылган. «Аның караву чималга бәйле кытлык күзәтелә», – диде ул. Сүзен дәлилләп: «Шул ук кәгазь җитештерүчеләр импорт химиясендә утыра», – дип тә өстәде. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, республикада җилем, аерым алганда, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, КАМАЗ өчен кирәк.

Казандагы «РТСИМ» оешмасы генераль директоры Айрат Мөхәммәтҗанов исә инженерлар әзерләргә ярдәм итмәкче. «Акыллы яшьләр күп, аларны эзләп табарга гына кирәк», – диде ул.

Моның өчен, мәсәлән, киберчемпионатлар үткәрүләрен дә сөйләде. Фикерне дәвам иттереп, Рөстәм Миңнеханов сәнәгать тармагына кирәкле белгечләрне кулына диплом алучылар арасыннан түгел, ә иртәрәк эзли башларга киңәш итте. Мәсәлән, инде дүртенче-бишенче курста белем алучылар арасыннан ук.

– Тегеләй-бу җитми, дип зарланырга кем дә оста, булганыннан файдалана белергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Эльвира ВӘЛИЕВА

БАТЫРЛЫК ИСТӘ

Ел саен 23 августта Совет гаскәрләренең Курск сугышында немец-фашист гаскәрләрен тар-мар итү көне (1943 ел) билгеләп үтелә. Шул уңайдан Татарстан Республикасы Премьер-министры Алексей Песошин халкыбызга мөрәҗәгать итте. Анда мондый юллар бар:

«Бөек Ватан сугышында Курск сугышы аерым урын алып тора. Ул 50 көн һәм төн дәвам итте һәм, Харьковны азат итеп, җиңү белән тәмамланды. Рәхимсезлеге һәм көрәштә ныклык күрсәтү ягыннан бу сугышның тиңе юк.

Бу – 80 ел элек Курск чыгынтысында нык торган һәм җиңә алган, совет халкының Җиңүенә нигез салган барлык кешеләрне искә алу көне. Курск янындагы бәрелеш Бөек Ватан сугышында кискен борылыш ясады.

Совет солдатларының тәвәккәллеге бөтен дөньяны аларның батырлыгы алдында баш иярга мәҗбүр итте. Утлы дугадагы сугышта катнашкан 100 меңнән артык совет сугышчысы батырлыклары, каһарманлыклары өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнде.

Бу сугыш һәм анда һәлак булганнар истәлегенә Россиядә Хәрби дан көне билгеләп үтелә, ә Курскида «Курск дугасы» Мемориаль комплексы төзелде.

Һәлак булганнар турында якты хатирәләр онытылмас! Якын кешеләрен сугыш тартып алган ватандашларыбыз алдында түбәнчелек белән баш иябез!»

Без бергә!

Дәүләт символы гына түгел. Татарстан Россия Дәүләт флагы көнен билгеләп үтү уңаеннан уздырыла торган чараларга кушылды. Республика халкы иң озын әләмне җилфердәтте, хорга кушылды.

• 22 августта Казан Кремле янында 50 метрлы ак-зәңгәр-кызыл әләм җәйделәр. Ул Идел буе федераль округындагы иң зур флаг булып танылды. Әлеге идеяне «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы бүлеге «Яшь гвардия» белән берлектә тормышка ашырды.

Флаг җәелдерүгә студентлар, хәтта үткән-киткән кешеләр дә кушылган. «Яшь гвардия»нең Казандагы бүлеге җитәкчесе, акцияне оештыручы Владислав Тарасов сүзләренчә, әлеге чараның патриотик максаты да бар.

– Яшьләр арасында ватанпәрвәрлек хисен арттыру, һичшиксез, мөһим. Без һәрвакыт илебез белән горурландык, горурланабыз һәм горурланачакбыз! – диде ул.

Дәүләт Советы депутаты Ольга Воронова, флаг берләштерү көченә ия, ди.

«Яшь гвардия» матбугат хезмәте

ӘЛӘМ БЕРЛӘШТЕРӘ

– Флаг – нәрсә ул? Ул – ышаныч, өмет, ярату, җиңү, бердәмлек символы. Россия – күпмилләтле дәүләт. Без бергә булырга, алдыбызда торган сорауларны бергә хәл итәргә тиеш, – диде ул, бәйрәм белән котлап.

• Истәлеккә калсын! Волонтерлар Бауман урамында бәйрәм уңаеннан төсле тасмалар тараттылар. Алар халыкка дәүләт флагының төсләре нинди мәгънәгә ия булуын аңлатты, әләмнең берләштерү символы икәнен әйтте. Әлеге акция кысасында 10 меңләп тасма таратылган. «Связь поколений» юнәлешенең Татарстандагы төбәк координаторы урынбасары Влада Волкова әйтүенчә, тасмаларны кулга алган кешеләр аңа горурлык хисләре белән караган.

– Флаг безне спорттагы җиңүләргә, фәнни ачышларга, яңа казанышларга, һөнәри батырлыкларга илһамландыра. Илнең теләсә кайсы кешесе әлеге тасманы патриотизм билгесе итеп тагып йөри алачак, – диде ул.

• Лагерь, мәктәпләрдә тантаналы линейка, флаг ясау буенча мастер-класс, күргәзмә, мәдәни-агарту чаралары, кызыклы флешмоблар узды.

• Башкаланың «Ак Барс Арена» стадионы һәм Казан циркы медиафасадларында Россия Дәүләт флагы көненә багышланган котлау язулары белән әләм төсләрендәге тематик сурәтләр урнаштырылды. Казан, Түбән Кама телебашняларын Россия триколоры төсләре бизәде.

• Татарстан Дәүләт камера хоры бөтенроссия хор акциясендә катнашты. Алар Олег Газмановның «Вперед, Россия!» җырына кушылды. Әлеге акциядә илнең төрле почмакларында яшәүче хор коллективлары катнашты.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

АВЫЛГА ҖИТМИ

Сәламәтлек сагында

Якын киләчәктә авылда эшләүче фельдшерларның ярдәмчеләре пәйда булачак. Татарстанда ФАПлардагы кадрлар кытлыгына каршы шул рәвешле көрәшеп карарга булганнар. Авыл, район җирлекләренә яшь белгечләрне дә көтәләр. Аларга шәһәрдәгегә караганда да күбрәк хезмәт хакы вәгъдә итәләр. Бу хакта Хөкүмәт йортында узган брифингта Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин сөйләде.

Ярдәмчесе булачак

«Медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасы үсеше» программасын тормышка ашыру өчен быел барлыгы 29,77 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Аның кысасында, иң беренче чиратта, профилактик тикшеренүләрне көчәйтергә җыеналар. Хәзерге вакытта Татарстанда 1463321 кеше профилактик тикшеренү һәм диспансеризация узган. Шуларның 20 меңнән артыгы аларны районнарга йөргән күчмә хастаханәләрдә үткән.

Якын арада авыл җирендәге ФАПларда фельдшер ярдәмчеләре эшли башлаячак. Марсель Миңнуллин сүзләренә караганда, Оренбург өлкәсендә бу тәҗрибә күптән гамәлдә.

– Яшерен-батырын түгел, кайбер районнарда, авылларда фельдшерларга кытлык. ФАП була торып та, эшләргә кеше юк, – диде министр. – Оренбург өлкәсендә Үзәк район хастаханәсе белән ФАПлар арасында ара ерак. Шуңа күрә анда фельдшер ярдәмчесе дигән яңа вазыйфа кертелгән. Ул – кече шәфкать туташы дигән сүз. ФАПлар булмаган урында алты ай дәвамында билгеле бер күнекмәләргә өйрәтү буенча укыту оештыралар. Фельдшер кадрлар кытлыгы мәсьәләсе шулай хәл ителә.

Сентябрьдән медицина көллиятендә булачак фельдшер ярдәмчеләре өчен кыска вакытлы курслар башларга җыеналар. ФАП булган һәр авылдан бер кеше укырга җибәреләчәк. Министрлыкта авылларга 1600ләп фельдшер ярдәмчесе кирәк дип исәпләп чыгарганнар. Курсларда аларны интернетта эшләргә, билгеле бер күрсәткечләрне (канда шикәр күләме, кан басымы, ЭКГ, сатурация h.б. күрсәткечләрне) сырхауханәдәге участок терапевтына җибәрергә өйрәтәчәкләр.

Авылларда яшь белгечләрне дә көтәләр. Министр яшерми: озак еллар дәвамында табиб булырга укыган яшь белгеч каланы салага алмаштырырга атлыгып тормый. Максатчан программа буенча укыган яшьләр арасында да үзен укыткан район дәвалау оешмасына кайтып эшләүдән баш тартучылар шактый.

Марсель Миңнуллин исә моны ялгыш фикер дип саный. Ник дигәндә, яшь белгечләр эшләргә кызыккан күппрофильле эре дәвалау оешмаларына ким дигәндә өч еллык өч стажың булганда гына эшкә урнашып була. Укып бетерүгә, шушы дәвалау оешмасы карамагындагы район, авыл җирлегендәге оешмаларда бер ел эшләп килгән яшь белгечне исә икенче елга ук бишкуллап эшкә алачаклар, дип ышандыра министр. Аларның хезмәт хакы да шактый аерыла.

Шәһәрдә эшләүче яшь табиблар күбрәк акча алып эшли дип уйлаучылар ялгыша. Киресенчә, авыл җирендә эшләүчеләрнеке күбрәк. Аларга хезмәт хакыннан тыш өстәмә акча, социаль түләүләр каралган. Чагыштыру өчен: югары технологияле медицина ярдәме үзәгендә эшләүче яшь табиб бүген уртача 55–60 мең сум хезмәт хакы ала. Район, авыл җирендә эшләүче белгечкә исә уртача 70 мең сум акча түләнә, – ди министр.

Кемгә – бүген, кемгә – иртәгә

Быел республиканың беренчел звено тармагында күңелле яңалыклар шактый булачак, дип ышандыралар. Хәтерләсәгез, 22 июнь көнне Дәрвишләр бистәсендә 6 нчы номерлы шәһәр балалар сырхауханәсенең бүлекчәсе ачылды. Август азагында Яшел Үзәннең Осиново бистәсендә дә күппрофильле яңа сырхауханә ачылыр дип көтелә. Марсель Миңнуллин сүзләренә караганда, «Салават Күпере» торак комплексындагы сырхауханә дә быел төзелә башлаячак. Чаллыдагы 5 нче номерлы шәһәр сырхауханәсе төзелешенә исә киләсе елда керешмәкчеләр.

– Киләсе елга Казанда 1 нче номерлы шәһәр балалар сырхауханәсенең яңа бинасы да төзелә башлаячак. Дөрес, Республика клиник балалар хастаханәсе иң төп дәвалау оешмасы булып тора. Әмма шәһәргә үз балалар сырхауханәсе кирәк, – дип ачыклык кертте министр.

Татарстанда трансплантация үзәге дә пәйда булырга мөмкин. Министр үзәкнең кайчан, кайда төзеләчәген өздереп әйтмәсә дә, республиканың аны үзендә булдырырга лаек икәнен искәртте. Саннар да шул хакта сөйли. Татарстан әгъзалар күчереп утырту буенча ясалган катлаулы операцияләр күләме буенча ил төбәкләре арасында алдынгы урында кала бирә.

– Трансплантация юнәлешендә ясалган операцияләр саны буенча быел Татарстан Шумаков исемендәге трансплантология үзәге белән Склифосовский исемендәге ашыгыч медицина ярдәме фәнни-тикшеренү институтыннан соң өченче урынга чыкты. Трансплантация үзәге – бик күләмле, өметле проект. Әмма ул республика гына түгел, федераль дәрәҗәдә булырга тиеш, – ди Марсель Миңнуллин.

«Татарстан Сәламәтлек саклау тармагының беренче звено тармагын модернизацияләү» программасын тормышка ашыру өчен быел барлыгы **2438,47** миллион сум акча бүлеп бирелгән.
Әлеге программа кысасында ел дәвамында республикада:
✓ 25 ФАП төзеләчәк, **117** медицина объекты (**9** сырхауханә, **4** участок хастаханәсе, **7** амбулатория, **96** ФАП) төзекләндереләчәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ӘҖӘТЛЕ ӘНИЛӘР

Борчыган мәсьәлә

Балаларын тәрбияләмәгән өчен хәтта әниләрдән дә алимент түләтәләр. Өч яшькә кадәрге сабыйлары булган әтиләр өчен яңалык бар. Хәзер алар хатыннарыннан «тәрбия хакы»н балага гына түгел, үзләренә дә таләп итә ала. Элек мондый хокук әниләргә генә бирелгән иде. Ел дәвамында республикада балалар файдасына 590 миллион (былтыр – 370 миллион) сум акча түләтелгән.

Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе матбугат үзәгеннән алынган мәгълүматларга караганда, бүген балигъ булмаган балаларына алимент түләтү буенча 2254 хатын-кызга карата эш ачылган. Узган елның шушы чорында андыйлар 2312 булган. Бигрәк тә Яшел Үзән, Түбән Кама районнары, Казан, Чаллы шәһәрләрендә баласын тәрбияләмәүче хатыннар күп. Алимент түләргә тиешле ханымнарның күбесе ана хокукыннан мәхрүм ителгән. Күбрәк опекуннар, балалар йортлары, интернат хезмәткәрләре алиментка бирә, әтиләрнең 10 проценты гына мондый адымга бара. Бу вакытта акча баланың банктагы исәп-хисап счетына күчә.

Әйтеп тә аңламагач, алимент түләмәүчеләргә карата катгый чаралар да күрергә туры килә. Иң нәтиҗәлесе – административ яки җинаять җаваплылыгына тарту. Әйтик, быел суд приставлары тарафыннан 237 административ беркетмә төзелгән. Газизләренә матди яктан ярдәм итүдән баш тарткан 112 хатын җинаять җаваплылыгына тартылган.

Алимент түләүче хатыннарның барысын да эчкече, гамьсез дип тә гаепләп булмый. Дөрес, гамьсезләре, тәртипсез тормыш алып барганнары күбрәк. Ир белән хатын арасындагы аңлашылмаучанлыклар, арага каенана-каената, туганнар кысылу да әлеге чиккә китерергә мөмкин.

– Мине әтием үстерде. Район үзәгендә яшәдек, аннан авыл егетенә кияүгә чыктым. Илгиз белән начар тормадык. Ике балабыз туды. Әмма әти авырый башлагач, ялгыз калдыра алмадым. Янына еш йөргәч, өйдә тавыш купты. «Син кайда йөрисең?» – дип, ирем көнләшә башлады. Түзмәде: «Йә әтиең, йә без!» – дип кырт кисте. Мин әтине сайладым. Балаларны ирем үстерә хәзер. Әле ярый булышырга кияүгә чыкмаган апасы бар. Ә мин алимент түлим. Тегүче булгач, тик тормыйм. Кемгә күлмәк, кемгә чалбар тегәм. Алимент буенча әҗәтем юк. Үз балаларым бит. Башка сыймаслык хәл. Әмма нишләтәсең? Башта балалар, әни безне ташлап китте, дип уйлады. Хәзер инде аралар җылынды, ятимлекне тоймыйлар, – ди 40 яшьлек Гөлнур ханым.

Казанда яшәүче Ринат Хәлиуллин да ике баласын ялгыз үстерә. Төрек кызы белән матур гына гаилә корган. Тик ун ел яшәгәч, аерылышканнар. Сәбәбе – мәхәббәт сүнү. Гамзә балалары белән телефоннан аралашып тора, елга бер мәртәбә башкалага да килеп киткәли.

– Ирем әйбәт, хурламыйм. Икебез дә мәгънәле. Тик мәхәббәт сүнгәч, бер-беребездән гаеп эзли башладык. Ә бу инде бизүгә китерде. Болай бер өйдә яшәү мөмкин түгел. Аерым торуың хәерле. Икебез дә икенче мәртәбә гаилә кормадык. Ирем мине алиментка бирмәде. Эшмәкәр бит, акчага кытлык юк. Минемчә, хатыннан алимент түләттерү ирләргә килешә торган гамәл түгел, – ди Гамзә.

Районнардагы вазгыятьне дә белештек. Балтач һәм Кукмара районнары суд приставлары бүлегендә, ирләр алиментка биргән очраклар берничә генә, диделәр. Ютазы районында алиментка 11 хатын тартылган, тик унысы акча түләми. Ә теге ананың 600 мең сум әҗәте җыелган. Хәзерге вакытта айга 5–6 мең сум түләргә тырыша. «Беркайда да эшләмәүче, эчеп, тәртипсез тормыш алып баручы аналар бу. Балаларын ирләре карый. Шуңа күрә яңа законны хуплыйбыз. Бу сабыйларын ялгыз тәрбияләүче аталарга ярдәм булачак», – дип белдерделәр район бүлегендә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Балалар әтиле дә, әниле дә булсын.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Эссен Продакшн АГ» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: коммуникацияләр буенча директор **Абдуллина** Адилә Илдус кызы, финанс директоры **Мәҗитов** Альберт Даил улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Туполев» гавами акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы хезмәткәрләре: станок җайланмалары һәм инструментлар ясау буенча 43 нче цех токаре **Гашиков** Әнвәр Әманулла улына, электр жгутларын җыю цехының җитештерүгә әзерлек цехы башлыгы урынбасары **Лядов** Александр Владимировичка, 78 нче цехның салкын штамповкалау җиһазлары көйләүчесе **Фәхретдинов** Рәдиф Фәрит улына, «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте хезмәткәрләре: тимерче-штамповкалаучы **Головнин** Дмитрий Александровичка, шомартучы **Гущин** Вячеслав Ивановичка, слесарь-инструментчы **Котдусова** Миләүшә Рафис кызына, бюро башлыгы **Соломатина** Ольга Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Эссен Продакшн АГ» акционер җәмгыяте генераль директорының производство буенча урынбасары **Есаулов** Роман Геннадьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Кама-Идел «КВАРТ» резин-техника акционер җәмгыяте» акционер җәмгыятенең 623 номерлы цехы автомобиль йөртүчесе **Әминов** Рафис Тимерша улына; «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Үзйөрешле моторвагоннар составы үзәк дирекциясе структур бүлекчәсе – Үзйөрешле моторвагоннар составы Горький дирекциясе структур бүлекчәсе – Казан моторвагоннар депосының шәһәр яны хәрәкәте локомотивлар бригадасы электр поезды машинисты **Бехтин** Сергей Александровичка; «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Тарту транспорты дирекциясе структур бүлекчәсе – Горький тарту транспорты дирекциясе структур бүлекчәсе – Юдино локомотивларны эксплуатацияләү депосының электровоз машинисты ярдәмчесе **Горохов** Владимир Викторовичка; «ЧАЛЛЫ СУДНОЧЫЛЫК КОМПАНИЯСЕ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Прага-14» земснаряды командиры – механигы **Гардиев** Рамил Заһит улына; Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Автомобиль юллары идарәсе автомобиль юллары бүлеге башлыгы **Идрисова** Фаина Тимерҗан кызына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ВАСИЛЬЕВ ЛЕВ БОРИСОВИЧ
(07.02.1925 – 21.08.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалту кичерде. 2023 елның 21 августында 99 нчы яшендә Кама автомобиль заводының беренче генераль директоры Васильев Лев Борисович вафат булды.

Л.Б. Васильев 1925 елның 7 февралендә Мәскәү шәһәрендә туган. Хезмәт эшчәнлеген мәктәп елларында йөкче булып башлаган. Бөек Ватан сугышы вакытында Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән, яраланган. Сугыштан соңгы елларда автобазада машина йөртүче булып эшләгән. 1948 елдан Мәскәү кече литражлы автомобильләр заводында төрле вазыйфаларда эшләгән, 1963 елда завод директоры булган.

1968 елда Л.Б. Васильев СССРның автомобиль сәнәгате министры урынбасары итеп билгеләнә, ә 1969 елда ул төзелә торган Кама йөк автомобильләре комплексының генераль директоры вазыйфасын да били. 1981 елдан СССР автомобиль сәнәгате министры урынбасары – Ленин комсомолы исемендәге автомобиль заводының генераль директоры булып эшли, 1984 елда СССРның Җиңел һәм азык-төлек сәнәгате һәм көнкүреш приборлары өчен машина төзелеше министрлыгын җитәкли.

Л.Б. Васильевның турыдан-туры җитәкчелегендә республикада рекордлы срокларда Чаллы шәһәрендә йөк автомобильләре җитештерү заводының беренче чираты эшләтеп җибәрелде. Катлаулы параллель проектлау һәм төзелеш шартларында ул техник проектны үз вакытында эшләүне, кирәкле документларны бирүне, шулай ук югары җитештерүчән җиһазларны сайлап алуны, әзерләүне һәм китерүне оештыруга иреште. Ул, төзүчеләр һәм монтажчылар белән бергәләп эшләү өчен, предприятиенең меңләгән кешелек коллективын туплый алды, ә бу «КАМАЗ» автомобильләрен җитештерүне графиктан алдарак башлап җибәрергә мөмкинлек бирде. Йөзгә якын фәнни-тикшеренү һәм проект институтларының, җиһазлар белән тәэмин итүче СССР заводлары һәм 700 чит ил фирмасының эшчәнлеген координацияләү алып барылды.

1976 елдан 1981 елга кадәр заводның төп конвейерында 200 меңнән артык йөк машинасы җыелган, автомобильләрнең 8 модификациясен серияле җитештерүне үзләштерелгән.

Җитештерү белән беррәттән, камазлыларның социаль мәсьәләләрен хәл итү аның эшчәнлегендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе була. Бу елларда Чаллы һәм Зәй шәһәрләрендә торак комплекслары, мәктәпләр, балалар бакчалары, балаларны сәламәтләндерү лагерьлары, медицина хезмәте күрсәтү объектлары төзелә.

1977 елда Кама йөк автомобильләре комплексын төзегәндә ирешкән уңышлары өчен аңа «Социалистик Хезмәт Герое» исеме бирелде.

Л.Б. Васильев сигезенче һәм тугызынчы чакырылыш ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Л.Б. Васильевның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм автомобиль төзелешен үстерүгә керткән зур өлеше югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләп үтелде, алар исәбендә Хезмәт Кызыл Байрагы, Октябрь Революциясе, Ленин, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орденнары, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Фидакарь хезмәт өчен», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медальләре бар.

Л.Б. Васильев һәрвакыт югары профессионализмы, гаҗәеп энергиясе, үзенә һәм кул астындагы кешеләргә карата таләпчәнлеге белән аерылып торды. Аның эшлекле һәм кешелек сыйфатлары, йөкләнгән эш өчен җаваплылык хисе, кешеләргә игътибарлы һәм сизгер мөнәсәбәте аңа зур абруй китерде, ул хезмәттәшләре һәм җәмәгатьчелек арасында танылу һәм тирән ихтирам казанды.

Васильев Лев Борисович турындагы якты истәлек безнең йөрәкләрдә гомерлеккә сакланыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ,
Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН,
Ә. Ә. СӘФӘРОВ, Р.К. ӘХМӘТШИН,
О.В. КОРОБЧЕНКО, Н.Г. МӘҺДИЕВ,
С.А. КОГОГИН, А.П. ЛАВРЕНТЬЕВ, Ш.Р. АГИЕВ

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Президиумы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, филология фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты

ЗӘКИЕВ Мирфатыйх Зәки улы

вафат булу сәбәпле, туганнарының һәм якыннарының олы кайгысын уртаклаша.

Рәсми хәбәр

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлеге, «КМПО-5» СНТ (кадастр кварталы 16:16: 212301) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 06.03.2023, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Семиозерка авылы, Югары ур., 99А й. (телефон: +7 (84365) 3-29-63) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 20 сентябрендә (14 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Биектау районы, Семиозерка авылы, Югары ур., 99А й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 28 августыннан 2023 елның 20 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 20 сентябреннән 2023 елның 25 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүмат сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Чернышевка авыл җирлеге, «Казанка-1» СНТ (кадастр кварталы 16:16:321001) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 06.03.2023, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клуб ур., 1 й. (телефон: +7 (84365) 73-5-05) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 20 сентябрендә (11 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клуб ур., 1 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 28 августыннан 2023 елның 20 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 20 сентябреннән 2023 елның 25 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүмат сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Осиново авыл җирлеге, Яңа Тура авылы (кадастр кварталы 16:20: 080202) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 06.03.2023, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Осиново авылы, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 1 й. (телефон: +7 (84371) 6-85-18) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы хакимиятенең (https://zelenodolsk.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 20 сентябрендә (15 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Яшел Үзән районы, Осиново авылы, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 1 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 28 августыннан 2023 елның 20 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 20 сентябреннән 2023 елның 25 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүмат сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге, Званка авылы СНТ (кадастр кварталы 16:33:080303) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 06.03.2023, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авылы, Комсомол ур., 13 й. (телефон: +7(84367) 40-1-81) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы хакимиятенең (https://pestreci.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 20 сентябрендә (09 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авылы, Комсомол ур., 13 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 28 августыннан 2023 елның 20 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 20 сентябреннән 2023 елның 25 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүмат сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Дачное авыл җирлеге, «Крутушка-1» СНТ (кадастр кварталы номеры 16:16: 213101) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 06.03.2023, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дачное авылы, Үзәк ур., 11 й. (телефон: +7 (84365) 78-3-33) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 20 сентябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Биектау районы, Дачное авылы, Үзәк ур., 11 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 28 августыннан 2023 елның 20 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 20 сентябреннән 2023 елның 25 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүмат сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

АЗӘРБАЙҖАН

Алексеевск

БЕР ЙОДРЫК

Җәмгыятьтә башкаларга яраклашсалар да, гаиләдә бары тик үз кагыйдәләре һәм тәртипләре белән генә яшиләр. Башка милләтләрне хөрмәтлиләр, ләкин үзләренеке – үзәктә. Алексеевск районының Родники авылында яшәүче Таһировлар белән гаиләдәге җылылык, туган якны сагыну һәм азәрбайҗаннарның язылмаган кануннары турында сөйләштек.

Тәнем генә монда

Гаилә башлыгы Афлан Таһиров Татарстанга 1986 елларда килеп урнашкан. Ул вакытта яшь егет төзелештә эшләп, бераз акча туплый да, туган ягында калган сөйгәне Кенуль белән туй үткәреп, аны да бирегә алып килә. Родники авылында аларның дүрт балалары туа.

– Татарстанда яшәвебезгә 40 ел була инде. Елга ике тапкыр туган якларыбызга да кайтып киләбез. Анда безнең туганнар, дуслар калды. Алар белән бик яхшы аралашабыз. Тормыш җилләре кая гына ташласа да, гаилә башлыгы туган җирендә йорт җиткерергә тиеш. Безне дә анда үз куышыбыз көтә. Чөнки беләбез: ни генә булса да, монда ничек кенә яхшы булса да, картайган көнебездә без барыбер туган якларыбызга кайтып китәчәкбез. Бу – һәр азәрбайҗан өчен язылмаган төп канун! Без монда тормыш иттек, балалар үстердек, укыттык, кияүләргә бирдек, өйләндерек, ләкин соңгы сулышыбызны туган ягыбызда алып, гәүдәбез аның туфрагына иңдерелергә тиеш, – диде гаилә башлыгы Афлан Таһиров.

Аның һәр сүзендә, һәр сулышында һәм хәрәкәтендә туган ягын, аның халкын яратуы һәм хөрмәт итүе сизелеп тора иде. Шуңа күрә безнең сак кына: «Туган якларыгызны сагынасызмы, Афлан әфәнде?» – дип әйткән сүзләребездән соң ул, кулын күкрәгенә куеп: «Тәнем генә монда, җаным, күңелем – тегендә», – дип әйтеп куйды да карашын читкә юнәтте.

Гаиләдә барысы да уртак

Таһировлар әйтүенчә, Алексеевск районында азәрбайҗаннар аз, шунлыктан алар белән аралашу юк дәрәҗәсендә. Родники авылында да алардан кала азәрбайҗаннар юк. Монда мордвалар гына яши.

– Шуңа күрә без мөмкинлек булганда Татарстан Халыклар дуслыгы йортына барабыз. Андагы концертларны карыйбыз, – диде Таһировларның өлкән кызлары Гөлнара ханым. – Йола, гореф-гадәтләребезне, телне саклау авыр, дип әйтә алмыйм. Чөнки син кайда гына яшәсәң дә, кайсы милләттән булуыңны истән чыгармыйсың. Чөнки ул – күңел түрендә саклана, кан белән буыннан-буынга тапшырыла торган хис. Без Татарстанда туып-үскәнгә күрә, русчаны бик яхшы беләбез. Акцентыбыз да юк. Мордвалар авылында яшәгәч, аларның да телен аңлыйбыз, аларны да хөрмәт итәбез һәм бәйрәмнәрен, гореф-гадәтләрен беләбез. Аларга да яраклашу бар. Ләкин үз туган телебездә дә иркен аралашабыз. Азәрбайҗанча уйлыйбыз, фикерлибез. Туганнар, дуслар, ватандашлар белән күрешкәндә туган телебездә аралашабыз. Ә менә гаиләдә, балалар белән күпчелек очракта русча сөйләшәбез. Әти-әни дә безнең белән күбрәк русча аралашырга тырышты, чөнки алар безнең телләрне бутавыбызны теләмәделәр, – диде Гөлнара ханым.

Алар, азәрбайҗан егете Абил белән гаилә корып, шушы ук авылда яшиләр.

– Иремне дә мин Казанда мәктәптә эшләгән вакытта очраттым. Иң элек әнисе белән аралаша башладык. Аннан соң әнисе булачак ирем белән таныштырды, – дип сөйләде ул танышу тарихларын. – Гомумән, безне әти-әни: «Сез азәрбайҗан, үз телегезне белегез, үз милләт вәкилләребез белән генә аралашыгыз, аңа гына кияүгә чыгыгыз», – дип, туктаусыз үгет-нәсыйхәт биреп үстермәде. Барысы да күңелдә иде.

Без, алар әйтмәсә дә, бары тик азәрбайҗан егете белән генә гаилә корачагыбызны аңлап, белеп үстек. Җәмгыятьтә бер төрле тәртипләр, кемгәдер яраклашу булса да, гаиләдә башка, бары тик үз кагыйдәләребез, үз телебез, үз ризыкларыбыз, үз йолаларыбыз, мәдәниятебез икәнен һәрвакыт белдек. Гаиләдә бүленеш булырга тиеш түгел, барысы да уртак булсын!

Без ирем белән үзара башлыча азәрбайҗан телендә сөйләшәбез. Аның әти-әнисенең гаиләсендә исә бары тик азәрбайҗан теле генә яңгырый. Шуңа күрә безнең балалар белән дә шул телдә генә сөйләшәләр.

Гөлнара белән Абил ике бала тәрбияләп үстерә. Эсмира белән Эльбрус та әти-әнисе шикелле үк рус телле балалар бакчасына йөри, рус мәктәбендә белем ала. Шунлыктан алар үз туган телләрен бик чамалы гына белә кебек тоелды безгә. Туган телдә китаплар, газета-журналлар да укымыйлар. Дөрес, Гөлнара ханым әйтүенчә, балалар азәрбайҗан телендәге мультфильмнарны, каналларны, китапларны интернеттан карый һәм укый, туган телләрендә музыка тыңлыйлар, аларга дини тәрбия бирелә.

– Булдыра алганча, мин оныкларым белән азәрбайҗан телендә сөйләшергә тырышам. Алар сөйләшмәсәләр дә, барысын да аңлыйлар, – диде Афлан әфәнде.

Таһировлар гаиләсе бик тырыш булып чыкты. Йорт-җирләре чиста-пөхтә, абзар тутырып мал-туар тоталар. Хуҗабикә җиде сыер сава, тугыз үгезләре, сарыклары бар. Балаларын да хезмәт белән тәрбияләгәннәр. Гаилә башлыгы шәхси «КамАЗ»ында ашлык ташый. Казан технология университетында укучы уллары Таһир да җәйге сезонда кырда иген суктыра. Хуҗабикә Кенуль исә авыл советында һәм почтада эшли.

Беренче ирегез – белем

Балаларына белем бирүне дә тормышларының иң төп бурычы итеп куюларын аңладык Таһировларның. Бер кызлары Гөлнара – укытучы, ике кызлары Фәридә һәм Арзу шәфкать туташлары булып эшли. Уллары Таһир да югары уку йортында белем ала.

– Мин балаларымның туган телләрен белүләрен телим, ләкин рус телендә иркен аралашулары белән дә горурланам, – диде гаилә башлыгы. – Минем өчен аларның югары белем алулары бик мөһим иде. Элек күп кенә азәрбайҗан гаиләләрендә хатын-кызлар эшләми, өйдә генә утыра, алар өчен белем алу да әһәмиятле түгел иде. Ә мин кызларымның белем алып, тормышта үз юлларын табуларын теләдем. Шуңа күрә аларны: «Сезнең беренче ирегез ул – белем! Ул ирдән мөһимрәк булырга тиеш. Гаиләдә ни булмас, хатын-кыз иренә генә таянырга тиеш түгел, аның үз-үзенә ышанычы булырга тиеш», – дип үстердем. Кызларымның холкына таянып, һөнәрләрен дә үзем сайладым.

Кызлары да сынатмаган, һәркайсы тормышта үз юлын тапкан.

– Безнең гаиләдә әти – һәрвакыт аерым бер авторитет. Мин кияүдә булсам да, аның сүзләренә колак салам, киңәшләшәм, хөрмәт итәм. Ни генә булса да, мин аңа таяна алачагымны беләм, – ди Гөлнара ханым.

Туй йолалары

Гөлнара ханым әйтүенчә, азәрбайҗан гаиләсендә күпчелек очракта булачак ир белән хатынны әти-әнисе сайлый. Әйтик, әгәр егет берәр мәҗлестә кызны ошата икән, ул бу турыда әти-әнисенә кайтып әйтә. Шуннан соң алар кызның әти-әнисе белән очраша. Егет белән кыз никахтан соң гына бер-берсе белән ныклап торып аралаша башлый.

Азәрбайҗан туйлары берничә көн дәвам итә һәм җырга-моңга бай була. Туйга бер көн кала кәләш йортында «Хна яхды» бәйрәме уздыралар. Монда кәләш белән кияүнең кыз туганнары һәм дуслары җыела. Кияүгә чыгачак туташ түргә утыра. Йөзен исә ал фата белән каплыйлар. Ал төс уңдырышлылык, Кояш һәм туган йортның җылысын аңлата дигән ышану бар. Ягъни фата булачак яшь хатынга бәхет һәм хәерле юл теләүне аңлата. Йортка килгән кызлар әти нигезеннән китүне аңлаткан йоланы башкара. Кәләшнең якын туганы кына салынган һәм буш савытларны кияүнең якын туганының алдына куя. Анысы исә буш савытка акча сала һәм кулына бераз кына алып, бии-бии кәләш янына килеп, аның кулларына, аякларына һәм чәчләренә сөртә. Кулларына бизәкләр төшерәләр. Шуннан соң кына буяучы кыз ике савыт белән башка кызлар янына килә. Алары кынаны алып, аның урынына акча сала. Бу кичне ут белән чистарыну йоласы да башкарыла. Моңа шәм яктысы кәләшне яман күзләрдән, бозымнардан һәм начар ниятле кешеләрдән саклар дигән мәгънә салынган. Кына бәйрәменең тагын бер атрибуты булып көзге санала. Кәләш аңа карарга тиеш була. Ул шулай ул начарлыктан саклауны аңлата.

– Әлеге традиция бик матур һәм серле уза. Бәйрәмдә биибез, җырлыйбыз. Яшь кияү шулай ук аз гына вакытка булса да бәйрәмгә килеп китә ала. Әлеге матур йола бүгенгә кадәр сакланып килә. Мин кияүгә чыкканда да шундый бәйрәм уздырдык. Тик хәзер аны өйдә ясамыйлар, күпчелек очракта ресторанда үтә. Үзебезнең балаларның да бу матур йоланы башкаруларын теләр идем, – диде Гөлнара ханым.

Азәрбайҗаннарда бирнә әзерләү йоласы да бар. Анысын, билгеле булганча, кыз гына хәстәрли. Зур, матур итеп бизәлгән савытларга (хонча) бүләкләр, бизәнгечләр, аксессуарлар, тәм-том, тормыш итәр өчен кирәк-яраклар тутырып, туй көнендә аны кияүнең йортына алып киләләр. Өйдән чыгып китәр вакыт җиткәч, ир туганы кәләшнең биленә җиде тапкыр кызыл тасма бәйләргә тиеш. Бу яшь гаиләнең җиде улы һәм ике кызы булсын, дигәнне аңлата, ди.

– Без бизәнгечләр, бигрәк тә алтын алка, йөзек, беләзекләр яратабыз, – ди Фәридә. – Кияү кәләшнең кулын сорарга килгәндә дә алтын эшләнмәләр алып килергә тиеш. Ул никадәр кыйммәтле булса, шуның кадәр яхшы. Аны кәләшнең бөтен туганнарына күрсәтеп чыгалар. Шулай ук кызның әнисенә дә кыйммәтле алтын йөзек бүләк ителергә тиеш. Бу йола да бүгенгә кадәр сакланган. Безнең туйда да барлык йолалар һәм гореф-гадәтләр үтәлде.

Милли ризыклар

Таһировлар белән очрашкач, азәрбайҗаннарның кунаклар каршы алуга, аларны сыйлауга һәм, гомумән, милли ризыклар әзерләүгә зур игътибар бирүен аңладык.

– Безнең милләт халкы башкалардан үзенең кунакчыллыгы белән аерылып тора торгандыр, – диде бу мәсьәләгә карата Гөлнара ханым. – Азәрбайҗаннарда өлкәннәрне хөрмәтләү дә көчле. Без кайда гына яшәсәк тә: ул ата-бабаларыбызның туган ягы булсынмы, яки чит җирләрдә гомер итсәкме, һәрвакыт өлкәннәргә кадер-хөрмәт күрсәтәбез. Моннан тыш, азәрбайҗан милләте үзенең ризыклары белән дан казанган.

Азәрбайҗаннарның күп төрле милли ризыклары бар: шах пылау, долма, боз баш (томат соусында аш), кюфта боз баш, ковурма, хашлама, душбара, кутаб, пәхләвә, шекер бура, пити, ләвәнге. Алар башка халыкларның сый-нигъмәтләреннән төрле тәмләткечләрне күп куллanулары белән аерылып тора. Шулай ук алар күпләп баллы ризыклар әзерләргә, сыйланырга ярата икән.

– Үзбәкләрдән аермалы буларак, бездә пылау дөге, ит, җимешләр һәм тәмләткечләр белән пешерелә. Кунаклар табынында һәрвакыт боз баш яки кюфта боз баш ризыгы куела. Шулай ук пылау һәм долмадан башка да берничек тә булмый. Һәм, әлбәттә инде, безнең табында чәйгә бик зур урын бирелә. Без кунакларны чәй белән каршы алабыз. Аның өчен махсус стаканнардан файдаланабыз, чәйгә төрле тәмләткечләр, үләннәрне күпләп салабыз. Әгәр, мәсәлән, ниндидер мосафир юл сорап тукталса да, без аны һәрвакыт чәйгә дәшеп алабыз, – диде Гөлнара ханым.

Болардан тыш, азәрбайҗан табынында төрледән-төрле җиләк-җимеш кайнатмалары күп.

– Ак эре чияне монда яратып бетермиләр. Ә безнең менә шуннан ясалган кайнатмага һушыбыз китә. Аны мондагы базарларда бик сирәк очратырга була. Без аны Азәрбайҗаннан кайтартабыз. Кызганыч, туган якларда аларның барысы да агачта пешеп утыра, ә монда сатып алып ясарга туры килә. Азәрбайҗаннарның символы булып гранат санала. Аның төсе – безнең иң яраткан төсебез, – дип елмая Кенуль ханым.

Аның сөйләвенчә, азәрбайҗан хуҗабикәләре табынны барысы да бергәләп әзерли. Һәм күпчелек эшләр урамда, саф һавада башкарыла. Бу вакытта ир-атлар чәй, каһвә эчеп, сөйләшеп утыра.

Сәхифәне Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде.
Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5129 данә
Гомуми тираж – 14057 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 319

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+